

Татарстанда 8-10 июль коннәрендә Татар теле һәм әдәбияты укытучыларынын Ботенроссия съезды vтте. Ботенроссия съездында Россиянен 32 тобәгеннән һәм Казахстаннан методистлар, РФнен милли мәгариф кураторлары, татар телле оешмалар житәкчеләре, татар оешмалары житәкчеләре, татар милли-мәдәни автономияләре житәкчеләре катнашты. Шул исәптән, Мордовиядән жиде делегат та бар иде. Алар - мәктәп укытучылары, директорлары һәм завучы, «Якташлар» жәмгыятчелегеннән - Асия Әхмәт кызы Агишева, Светлана Равиль кызы Поташева,  Луиза Низаметдин кызы Смакаева, Сания Спартак кызы Саляева, Рима Хәмзә кызы Рахмятуллова, Халисә Сафиулла кызы Кугушева,  Тәнзилә Әхмәт кызы Утешева.       Татарстан Республикасында татар теле һәм әдәбияты укытучылары, татар этномәдәни компонентлы мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре VII Ботенроссия съезды пленар утырышында Татарстан Республикасынын фән һәм мәгариф министрынын беренче урынбасары Илсур Хадиуллин да катнашты.

Пленар утырыштан сон, теләк белдергәннәр, татар театрын карап кайтканнар.

Икенче конне Кукмара районында съезднын кvчмә утырышы vтте. Дvрт секциядә «Милли мәгариф заманча таләпләр контекстында: чакырулар, проблемалар, чишv юллары», «Баланын милли vзанын һәм шәхесен формалаштыру факторы буларак поликультуралы белем бирv», «Заманча таләпләр кысаларында татар телен һәм әдәбиятын укытуда нәтижәле технологияләр»,  «Этномилли белем бирvне vстерvдә хакимият органнары һәм милли-мәдәни автономияләрнен vзара багланышлары» дигән мәсьә-ләләр яктыртылды. Моннан тыш, съезд кунаклары районнын белем бирv оешмаларында да булдылар. Делегатлар Кукмарада Зур Сәрдек авылыныда гимназия һәм  «Йолдызлык», «Кынгырау» балалар бакчалары белән танышты, кунаклар хормәтенә оештырылган матур концертны рәхәтләнеп карадылар. Секция утырышларында, милли мәгарифкә кагылышлы тvгәрәк остәлләрдә татар теленен бvгенге торышы турында сойләгәннәр. Рузаевка районы

